| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ** |
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» декабрь 2021 с. Тюлячи № 324

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 31 декабрендәге 618 номерлы «Теләче муниципаль районы бюджетыннан муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләргә муниципаль биремне үтәүне финанс белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 1662 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 31 декабрендәге 618 номерлы «Теләче муниципаль районы бюджетыннан муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләргә муниципаль биремне үтәүне финанс белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карар белән расланган Теләче муниципаль районы бюджетыннан муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләргә муниципаль биремне үтәүне финанс белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү Тәртибенә:

- 2.7 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) максатчан субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән милли яисә региональ проектлар нәтиҗәләренә (мондый проектны гамәлгә ашыру максатларында субсидия бирелгән очракта) һәм Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән субсидия бирү нәтиҗәләре типларына туры килергә тиеш, ул Россия Финанс министрлыгының 2021 елның 29 сентябрендәге 138н номерлы боерыгы белән расланган субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибе нигезендә билгеләнгән субсидияләр бирү типларына туры килергә тиеш;»;

- 3.1 пунктта «финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында» сүзләреннән соң «(әмма кварталга кимендә бер тапкыр)» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин